МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

20.03.2023 № 76

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 17.03.2016 № 111 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы комиссиясе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 ел 26 нчы гыйнвар № 1-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) Администрациясе турында» 2023 ел 4 нче февраль № УП-68 Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының норматив хокук актын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының (алда – Татарстан Республикасы ГТХМ) 17.03.2016 № 111 боерыгы белән расланган (16.01.2018 № 31 Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы комиссиясе турында Нигезләмәгә алдагы үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясен, федераль законнарын, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан

Республикасы законнарын, әлеге Нигезләмәне, шулай ук Татарстан Республикасы ГТХМ актларын куллана.»;

7 нче пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе идарәсе вәкиле»;

9 нчы пунктта «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе белән килешү буенча» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе белән килешү буенча» сүзләренә алыштырырга;

21 нче пунктны «кызыксынган оешмалар» сүзләреннән соң «, коррупциягә каршы тору өлкәсендә «Посейдон» дәүләт мәгълүмат системасын куллану, шул исәптән сораулар җибәрү өчен» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасы ГТХМ министр урынбасарларына, структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә җиткерергә.

Министр вазыйфаларын
башкаручы Т.В. Кәримуллин